**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «7» июленнән № 24-188

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-174 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33., 39.36 статьялары, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән расланган «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә дә, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июнендәге 498 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-174 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2009 елның 05 июлендәге 50-301 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 4.3. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү хокукына сатуларда шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары

һәм» һөнәри керемгә салым»махсус салым режимын кулланучы, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына дәгъва кылучы физик затлар катнаша ала».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов